# КАРАР

**24 ноябрь 2021 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Мәчкәрә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 18 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Мәчкәрә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 900 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Мәчкәрә авылы , Октябрь тыкрыгы юлларына вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Мәчкәрә авылы, Луговая урамы буенча вак таш җәелгән юлларның профилен төзәтү (килешү буенча түләү);
- Су башнясы өчен насос алу (килешү буенча түләү);
- Янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү);
- Мәчкәрә авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча түләү);
- Зиратларны карап тоту, материаллар алу, койма урнаштыру, инвентарь алу (килешү буенча түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 156 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 100 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 100 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Мәчкәрә авылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Мәчкәрә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 900 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Мәчкәрә авылы , Октябрь тыкрыгы юлларына вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Мәчкәрә авылы, Луговая урамы буенча вак таш җәелгән юлларның профилен төзәтү (килешү буенча түләү);
- Су башнясы өчен насос алу (килешү буенча түләү);
- Янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү);
- Мәчкәрә авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча түләү);
- Зиратларны карап тоту, материаллар алу, койма урнаштыру, инвентарь алу (килешү буенча түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Күкшел авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Хәмидуллин

ОГРН 1021607753298
ИНН 1623002022